РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

24 июля 2018 г. № 172

Хезмәт тәртибенә карата таләпләр
үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын
җайга салу буенча комиссия турында
нигезләмә раслау хакында

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы

КАРАРЫ

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы КАРАР итте:

1. Хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын. җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын. җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне раслау” 2016 елның 16 июнендәге 47-номерлы КАРАРЫН көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Интернет челтәрендәге хокукый мәгълүматлар рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасы Чирмешән муниципаль районының мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылганнан соң көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чирмешән муниципаль районының җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртипләре, экология һәм халык иминлеге буенча Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Совет рәисе,
Район башлыгы Ф.М. Дәүләтшин